| МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

16.01.2018 № 31

**2016 ел 17 март Татарстан Республикасы ГТХМ боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә салынган таләпләрне үтәү һәм кызыксыну конфликтларын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр комиссиясе турында кагыйдәнамәгә үзгәрешне кертү турында**

“Коррупциягә каршы тору турында законнарны үтәү контролен көчәйтү максаты белән Русия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләрне кертү турында” 2017 ел 19 сентябрь № 431 Русия Федерациясе Президенты Указына һәм “Коррупциягә каршы тору сораулары буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләрне кертү турында” 2017 ел 11 декабрь № УП-1092 Татарстан Республикасы Президенты Указына туры китереп, б о е р а м:

1. 2016 ел 17 март Татарстан Республикасы ГТХМ боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә салынган таләпләрне үтәү һәм кызыксыну конфликтларын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр комиссиясе турында кагыйдәнамәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

21 нче пунктка абзац өстәргә:

“Биредәге Кагыйдәнамәнең 17, 19, 20 нче пунктларында язылган дәлилләнгән йомгаклар түбәндәгеләрдән торырга тиеш:

а) биредәге Кагыйдәнамәнең 15 нче пунктның “д” пункт астында “б” пункт астында икенче һәм бишенче абзацларда билгеләнгән мөрәҗәгатьләрдә яисә белдерүләрдә язылган мәгълүматтан;

б) дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан сорау нигезендә алынган мәгълүматны;

в) биредәге Кагыйдәнамәнең 15 нче пунктның “д” пункт астында “б” пункт астында икенче һәм бишенче абзацларда билгеләнгән мөрәҗәгатьләрне һәм белдерүләрне алдан карап тикшерү нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән йомгактан, шулай да биредәге Кагыйдәнамәнең 30, 34, 36 нчы пунктларына туры китерелгән карарларның берсен яисә башка карарны кабул итәр өчен тәкъдимнәрдән”.

2. Биредәге боерыкны министр урынбасарларына, министрлыкның структура бүлекләренең җитәкчеләренә һәм дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә җиткерергә.

3. Биредәге боерыкны үтәү контролен министр урынбасары О. А. Степущенкога йөкләргә.

Министр Р. Җ. Хәбибуллин